РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

__16.01.2026___ **Чистай шәһәре** №__12___

«2026 елга социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен торак урыннарны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре, шулай ук гомуми җыелышында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» торак фондында торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре өчен түләү күләмен раслау хакында»

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, шулай ук Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча Методик тәкъдимнәрне раслау хакында» 06.04.2018 ел, № 213/пр боерыгы белән расланган, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 № 33-ФЗ Федераль законы һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләрен, шулай ук гомуми җыелышында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең торак фондында торак урынны карап тоткан

өчен түләү күләмен 13,4 процент күләмендә билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләрен, иң чик (максималь) индексын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://chistopol.tatar.ru/).

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты
җитәкчесе А.Р. Хаматов